**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «16» мартыннан

№ 32-252

2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Росси Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 2 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмә турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уствы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмәмуниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү мәҗбүри булып тормый.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга. http://pravo.tatarstan.ruhttp://novosheshminsk.tatarstan.ru/
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов